Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Советының утызынчы утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

23 октябрь, 2023 ел № 80

Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге торак пунктлары территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы 2019 елның 08 ноябрендәге 54 номерлы (2021 елның 17 декабрендәге 35 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) Шигали авыл җирлеге Советы карары, имзалар кәгазьләре нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. Шигали авыл җирлегенең торак пунктлары территориясенең бер өлешендә түбәндәге торак пунктларда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Иске Шигали авылында. 2 нче Урман урамы гражданнары өчен 2023 елның 6 ноябрендә 11.00 сәгатьтә Үзәк урамындагы 45 нче йорт адресы буенча авыл мәдәният йорты бинасында гражданнар җыенын үткәрергә.

. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2024 елда Шигали авыл җирлеге Иске Шигали авылы 2 нче Урман урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 8000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Яңа Шигали авылында. Груша, Алмалы, Бәхетле, Чияле, Земляничная, Җиләкле, Рябиновая, Бакча, Ореховая, Сливовая, Малиновая, Татарстан, Черешневая урамнары гражданнары өчен 2023 елның 6 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Үзәк урамындагы 45 нче йорт адресы буенча авыл мәдәният йорты бинасында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2023 елда Шигали авыл җирлеге Иске Шигали авылы Груша, Алмалы, Бәхетле, Чияле, Земляничная, Җиләкле, Рябиновая, Бакча, Ореховая, Сливовая, Малиновая, Татарстан, Черешневая урамнары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- балалар мәйданчыгын төзү һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү;
урамнар яктырткычларын ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Шигали авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башлыгы В.М. Сәлимов